СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НОРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

*24 декабрь, 1997ел.*
*ЧӘРШӘМБЕ*

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.* | *№ 144 (8156)* | *Бәясе билгеләнгәнчә*

## Район тормышы: вакыйгалар, фактлар

**Яңалыклар**

### Дискотека. Балалар үзәгендә

Узган якшәмбедә балалар-яшүсмерләр үзәгендә үткән дискотека традициягә керер,мөгаен.

Дискотека була!Бу хәбәр балалар-яшүсмерләр үзәге түгәрәкләрендә шөгыльләнүче балаларга килеп ирешкәч,шәһәрнең бөтен мәктәпләренә дә таралды. Шуңа да якшәмбе көнне үзәкнең актлар залы балалар белән шыгрым тулы иде. Ә җыр-музыка озак яңгырады ул көнне.Балалар рәхәтләнеп биеделәр,лотерея уйнатуда катнаштылар.Параллель рәвештә теләүчеләр үзәк каршында стационар эшләүче түгәрәкләрдә дә шөгыльләнделәр.

### Олимпиадалар дәвам итә

Район белем бирү учреждениеләрендә фән олимпиадалары тәмамланып килә.Теге яки бу фән буенча хәзерлекләре югары булган һәм мәктәптә призлы урыннарга чыгып, район олимпиадаларында катнашу хокукын яулаган укучылар дулкынландыргыч мизгелләрне кабат кичерәчәкләр әле.

Район мәгариф бүлеге район олимпиадалары үткәрүне уңышлы оештырып җибәрде. Математика, физика буенча үткән олимпиадалардан соң республика масштабында район данын яклаячак укучылар исемнәре билгеле инде. Гомумән алганда, быел 15 фән буенча 19 төр олимпиада үтәчәк.





Илгизә Кәлимуллина (рәсемдә) - «Киекле» хуҗалыгының Кизләү бүлекчәсендә намуслы хезмәте белән ихтирам казанган терлекчеләрнең берсе. Хәзерге вакытта ферманың бозаулату бүлегендә эшли ул. Өлкән хезмәттәше Сания апа Кәримова белән бер - берсен ярты сүздән аңлап, булсынга дип тырышып йөрүләре: Илгизә сыерларны бозаулатып, бозаулаганнарын карап - савып торса, Сания апа яшь үрчемне кадерләп тәрбияли. Тырыш хезмәтләренең нәтиҗәсе дә күркәм: хуҗалыкта сыерлардан үрчем алу да әйбәт, җиренә җиткереп карау, шул исәптән бозауларны салкында асрау алымын да кыю куллану нәтиҗәсендә бозауларның сакланышы яхшы, артымы канәгатьләндерерлек.

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

### Поселогыбыз иң матуры булыр



Яңа ел- минем иң яраткан бәйрәмнәремнең берсе.Төрледән-төрле утлар,ялт-йолт килеп торучы гирляндалар,зифа урман кунагы-чыршы,бәйрәм күңел ачулары күңелемә бик тә якын.Узган ел бу бәйрәм өлкәннәр,шулай ук без, яшүсмерләр өчен күпме шатлык китерде.Безнең шикәрчеләр поселогы микрорайоннар арасында иң матуры булгандыр,мөгаен.Мәктәбебезнең бизәлеше дә гомердә булмаганча иде.

Вакыт ничек тиз үтә.Инде менә Яңа ел да җитеп килә.Ул ничек үтәр икән.Берничә көн элек поселокта башланган җанлылык поселогыбызның былтыргыдан ким бизәлмәсенә ышанычны ныгыта.Үз чыршыбыз булыр,урамнарыбыз төрле-төрле утлар белән яктыртылыр,административ биналарның һәрберсе үзенчә бизәлер дигән өмет ныгый күңелдә.Шикәр кайнатучылар арасында балкон-тәрәзәләрен бизәп,конкурста катнашырга теләк белдерүчеләр дә табылмый калмастыр,минем...

Мәктәбебез дә Яңа елга хәзерлекне күптән башлады инде.Бәйрәмебезне үткәрү буенча төп мәшәкатьләр укытучыларыбыз А.А.Щербакова,В.Ю.Самойленко,О.Г.Сергеева өстендә.

Өлкән класслар укучылары да аларга теләп булышалар.Һәр класс Кыш бабайдан задание алды инде.Яңа ел плакатлары,яраткан әкият геройлары сурәтләре трафаретлары,төсле чылбырлар ясау,залны бизәү һ.б. Кыш бабай һәм Кар кызы рольләре дә билгеле.А.Синяков,О.Тихонова,А.Членов,Л.Лобачева кебек укучылар аны менә инде берничә ел рәттән уңышлы башкаралар.Музыка кабинетында исә иртәдән кичкә кадәр җыр тынмый,әледән-әле шигырь сөючеләрнең тавышы ишетелә.

Гомумән,көтеп алган бәйрәмебезгә көннән-көн азрак вакыт кала.Күңелле итеп үткәрәсе иде аны.

**Д.ГАЛИЕВА.**
**Норлат шәһәре.**

### Ул һәрчак алдынгы булды

Рәис Гайнетдинов.Хуҗалыкта үткән җыелыш,башка төрле чараларда аның исеме иң алда телгә алына.Шулай булмыйни:иң алдынгы механизаторларыбызның берсе бит ул.ДТ-75 тракторына утырып эшләвенә 28 ел булды быел.Җир сөрде,чәчте,юл чистартты,йөк күчерде ул.Гомумән,шушы елларда ул башкармаган эш калмагандыр,мөгаен.Ә аңа кадәр фермада терлекләр караган иде Рәис.Бергә эшләдек без аның белән.Хезмәтенә һәрчак җитди карады ул.

Күптән түгел Р.Гайнетдиновка 60 яшь тулды.Әмма яшем тулды дип эшеннән китәргә ашыкмый әле Рәисебез.Хәзер дә техника ремонтлау белән мәшгуль, язга тракторына утырып,басуга иген игәргә чыкмыйча түзмәстер.

**С.ФӘТХЕТДИНОВА,**
**хәбәрче.**
**Яңа Әмзә авылы.**

**Кискен сигнал**

### Кыш уртасында сөт ачыталар

**Җәй көне «Алга» хуҗалыгыннан сөт - май комбинатына китерелә торган продукциянең ачылыгы нормадан югары булган очраклар турында хәбәр иткәли идек инде. Баксаң, сөтнең әчүенә һич тә җәйге көннең эссесенә генә гаепле түгел икән - хуҗалыктан кыш уртасында китерелгән продукциянең дә әчелеге 30 градустан артып киткәли. Әле шушы арада гына шул сәбәп белән бер көнне 3 тонна, икенче көнне 1,7 тонна сөтләрен кире бордылар. МСО ярдәмче хуҗалыгында да 9 центнердан артык продукцияләрен кире боруларына аптыраганнардыр. Тик, ни хәл итәсең, әчегән сөтнең кемгә кирәге бар ди?**

## Булган малны бәрәкәтле тотарга кирәк

Район хуҗалыклары быел унбер айда 4456 тонна ит урнаштырдылар. Бу - планлаштырылганга карата 137 процент тәшкил итә. Шул исәптән дәүләт ресурслары исәбенә тапшырылган ит 2576 тонна булды. Анысы узган елгыдан 103 процентка артыграк булса да, еллык план дәрәҗәсенә җитешми әле. Дөрес, «Родина», Кузнецов исемендәге, Синдряков исемендәге хуҗалыклар планнарның ике төрен дә күпкә арттырып, шул исәптән дәүләт ресурсларына ит тапшыруны 164 - 193 процентка үтәделәр. Соңгысын Хафизов исемендәге хуҗалык та 115 процентка башкарды инде.

Шул ук вакытта дәүләт ресурсларына ит тапшыру буенча контрактация килешүләрен санга сукмаучы хуҗалыклар да бар әле. Әйтик, Мичурин исемендәге хуҗалыкның унбер айда саткан итенең биштән бере генә диярлек дәүләт ресурсларына тапшырылып, калганы башка каналлар буенча киткән. «Игенче», «1 нче Май», «Якты Күл» хуҗалыкларында, МСО ярдәмче хуҗалыгында да башка каналлар буенча киткән ит дәүләт ресурсларына тапшырылганыннан өч, «Үрнәк»тә алты тапкыр артыграк.

Итне, шул исәптән аяклы малны да чит каналлар буенча озату акыл беләнрәк эшләнсә бер хәл әле. Әйтик, «Рассвет» хуҗалыгының башка каналлар буенча урнаштырган ите дәүләт ресурсларына сатылганыннан ике тапкырга диярлек күбрәк. Әмма, бердән, хуҗалык дәүләт ресурсларына ит сату планын тутырды диярлек инде, икенчедән, башка каналлар буенча сатылганы да файдалы шартларда урнаштырылган. Әйтик, ул итне Норлат ит комбинатында эшкәртеп казылык әйберләренә әйләндереп сату хуҗалыкка 223 миллион сум саф табыш биргән, тереләй авырлыктагы итнең килограммы 6300 сумнан туры килгән. Кондициясез ул терлекне дәүләт ресурсларына тапшырган очракта хуҗалык киресенчә 439 миллион сум зыян күргән булыр иде.

Кызганычка каршы, кайбер хуҗалыкларда мәсьәләгә шулай хуҗаларча караш җитми әле. Нәтиҗәдә тиешле авырлыкка җитмәгән яки арык терлекләр суела, алар арзан бәягә сатыла һәм хуҗалыкка шактый зыян килә. Әйтик, «Якты Күл», «Киекле», «Игенче», «Төрнәс», Мичурин исемендәге хуҗалыкларда, МСО ярдәмче хуҗалыгында суелган мөгезле эре терлекнең уртача авырлыгы 204 - 250 килограммнан, нәтиҗәдә аларны сату бәясе дә 3852 - 5000 сумнан артмаган. Эчке ихтыяҗларга суелган дуңгызлар белән дә шундый ук хәл.

Шуңа күрә дә район хакимияте, авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе ит ресурсларын бәрәкәтсез тотуга юл куйган хуҗалык җитәкчеләрен каты кисәтергә һәм аларның игътибарын бу мәсьәләдә хуҗаларча эш итәргә кирәклегенә юнәлтергә мәҗбүр булды.

### Котлыйбыз !

***«Норлат машина төзү заводы» акционерлык җәмгыяте коллективы генераль директоры Жемков Юрий Михайловичны «Россия торак-коммуналь хуҗалыгының мактаулы хезмәткәре» исеме бирелү белән котлый,зур иҗади уңышлар,нык сәламәтлек,гаилә иминлеге тели.***

## Камышлы янында трагедия

Дәүләт автоинспекция бүлеге чираттагы автокатастрофа нәтиҗәсендә юлда кешеләр үлеме турында кайгылы хәбәр җиткерә.Бу хәбәрләргә күнү җиңел түгел,бу юлы исә күпне күргән ДАИ хезмәткәрләре үзләре дә чын психологик шок кичерәләр.

Трагедия Норлат-Әлмәт трассасында Урта Камышлыдан ерак түгел салкын буранлы 20нче декабрьдә була.Дәүләт номеры Е 479 ЕМ булган ВАЗ 2108 шоферы С. һәм аның 5 пассажиры -алар арасында 6 яшьлек Р.Хәлимов,әбисе 72 яшьлек Г.Мөхәммәтҗанова,әнисе 31 яшьлек Р.Хәлимова да була- Түбән Камадан Чулпанга армиягә озатырга кайтып баралар.Бу урынга алар иртәнге 9нчы яртыларга килеп җитәләр.Юлда буран себерү сәбәпле күз күреме начар була.Шул шартларда Жигули алдагы машинаны узарга тели,әмма идарә итүне йомшартып,сулга китә һәм каршы килүче ГАЗ- 53 машинасына килеп бәрелә.Бу Самара өлкәсенең Отрадный шәһәреннән В. машинасы була.Авария нәтиҗәсендә ике пассажир - әнисе белән кызы урында һәлак булалар, ә калган пассажирлар төрле дәрәҗәдәге тән җәрәхәтләре алалар.6 яшьлек малай күп сынулар нәтиҗәсендә район үзәк шифаханәсенә китерелә.Шулай кыска вакыт эчендә Жигули шоферының ваемсызлыгы аркасында бер гаиләгә ике кайгылы хәбәр килә һәм 6 яшьлек малай ятим булып кала.

## Россиянең сугышчан дан көннәре



### 24 декабрь - А.В.Суворов җитәкчелегендәге рус гаскәрләренең Измаилны алу көне

Рус - төрек сугышында (1787 - 1788еллар) Плевна, Кинсбург, Очаков, Рымник өчен сугышларда җиңелгән Төркия, солых төзелүгә дә карамастан, 1790 елда сугыш хәрәкәтләрен кабат яңартып җибәрә.

Россия бу сугышта үз алдына Кара диңгезгә чыгу һәм Балканда үзенең йогынтысын көчәйтүне максат итеп куя. Беренче уңышлар бик җиңел яулана. Ишкәкле флотилия Дунайдан төрек көймәләрен себереп чыгара. Килия, Тульча, Исакча алына. Әмма Дунай тамагында төрекләрнең, Суворов сүзләре белән әйткәндә «йомшак урыннары булмаган» ныгытылган Измаил крепосте тора.

Француз инженерлары тарафыннан үзгәртеп корылган һәм ныгытылган бу крепость чамадан тыш биек вал белән, ә анысы су тутырылган киң канау белән чорнап алынган була, шәһәрнең аңа килү юлларын, капкаларын, бастионнарын 260 орудие саклый. Измаил өчен сакта төрекләрнең » 35 меңлек иң яхшы гаскәрләрдән сайлап җыелган гарнизоны сакта тора.

Руслар үз гаскәрләрен Измаилга таба якынайталар. Бирелергә дигән тәкъдимгә каршы төрекләрнең башлыгы, крепостьны бирүгә караганда үлүебез яхшырак, дип көлеп кенә җавап кайтара.

Рус гаскәрләренең саны 30 меңгә җитә яза, аларның яртысы начар коралланган казаклар була. Солдатларның киемнәре тузып бетә, азык - төлек җитмәве үзен нык сиздерә.

Вакыт уза, ул арада инде салкын һәм юеш көз килеп җитә. Солдатларның да сугышчан рухы төшә. Генераллар Потемкин, Майоров, Гудовичтан торган хәрби совет штурмнан баш тартырга һәм гаскәрне кышкы фатирларга чигереп торырга карар кылалар.

Әмма Екатерина II моңа риза булмый һәм сугышны тизрәк һәм җиңү белән тәмамлауны таләп итә. Ул бөтен гаскәрне үз командалыгына алырга тәкъдим итеп Суворовка чапкын җибәрә.

Суворовның килүе турындагы хәбәр армия һәм флотка тарала һәм «Суворов» дигән сүз үзе генә дә арасында моңарчы күрелмәгән сугышчан рух күтәренкелеге уята. Крепостьны штурмлауга әзерлек башлана. Суворов чатырлар буйлап йөри, солатлар белән сөйләшә, азык - төлек китерергә, күрәк иттереп баскычлар әзерләргә боерык бирә.

Измаилдан читтә сулы канаулы ныгытмаларына кадәр ясап шуңа охшаш крепость төзелә. Солдатлар төннәрен монда килеп шул канау аркылы чыгарга, ныгытма вал өстенә менәргә, штык сугышына өйрәнәләр. Флангларда яңа батареялар корыла.

Крепостьны Дунайдан да десант төшереп өч яктан берьюлы штурмларга карар кылына.

Мәгънәсез кан коюны булдырмас өчен Суворов Мехметкә креспотьны бирергә тәкъдим итеп язу җибәрә. «Уйларга 24 сәгать вакыт - сезнең иркегез; минем яктан беренче туп атуы - иркегез бетә башлавы; штурм - үлем» диелгән була анда. Төрекләр крепостьны сугышсыз бирүдән баш тарталар.

Рус гаскәрләре атакага тотынып өчен башлангыч позициягә урнашалар. 24 декабрь иртәсендә һавага сигнал ракетасы очырыла. Солдатлар штурмга күтәреләләр. Канау аркылы баскычлар салып узалар, ә аннан баскычларны икешәрләп бәйләп вал стенасына менәләр. Төрекләр мылтык һәм картечьлардан рәхимсез ут ачалар. Күп югалтуларга да карамастан, рус гаскәрләре төрекләрнең кылыч һөҗүмнәренә каршы штык атакасы ясыйлар. Сугыш кызганнан кыза бара, һәркайда русча «ура!» яңгырый.

Гренадерлар, карабинерлар һәм гусарлар ачык капкадан крепость эченә атыла. Төрекләр кыю төстә каршы торалар, һәр йорттан ядрәләр оча. Постоялый дворлар үзләре кечкенә крепостьларга әверелә. Рәхимсез штык сугышында аны чолгап алган берничә мең төрек белән Пирей үтерелә. Сераскир Мехмет та шундый ук язмышка дучар була. Дошманның каршылыгы бастырыла, Измаил алына.

Бу сугышта төрекләрнең 26 мең сугышчысы үлә, 9 мең кешесе әсирлеккә алына. Русларның 4 мең кешесе үлә, 6 меңе яралана. Руслар 245 туп, 3 мең пот дары, 341 байрак, 10 меңләп ат кулга төшерәләр.

Измаилның яулануы Төркиягә һәм Россиянең дошманнарына гаять көчле тәэсир ясый. Суворовның бу данлыклы җиңүе рус коралының һәм рус сугыш сәнгатенең бөтен дөньяда данын арттыра һәм рус - төрек сугышының тәмамлануын тизләтә.

**Язманы И.САНДЛЕР әзерләде.**

# Тиеннәр һәм берлек

***Январьда безне нәрсә көтә дигән сорауга һәркем уйлап та тормыйча җавап бирә:яңа 1998 ел башы һәм денаоминация.Беренчесе белән гадәттә иң якты өметләр бәйләнсә,икенчесе шулай ук борчылырга нигез калдырмый, акча алышынмый,кешеләргә ашыга-кабалана чиратка йөгерәсе юк.Бары иске акча берәмлекләрен акрынлап әйләнештән чыгаралар һәм яңа,элек без күнгән берәмлекләр кире кайтачак.Нульләре кимегән яңа куперлар әйләнешкә керүгә берничә көн генә калды,шуңа без Норлат расчет-касса үзәге начальнигы Асия Котбетдиновна Сафиуллинага бу җәһәттән берничә сорау белән мөрәҗәгать иттек.***

# Кире кайта

## Беренче куллардан

**-Асия Котбетдиновна,деноминация районда сездән башлангыч ала булып чыга.Тагын бер кат аның эчтәлеген аңлатсагыз иде.**

-Деноминация-бу инфляция тукталу, икътисад стабильләшү,акча керемнәре үсүгә күргәзмә дәлил.Һәм ул барлык акча әйләнешен гадиләштерү һәм арзанайту өчен башкарыла,чөнки бәяләрнең яңа масштабына хезмәт күрсәткәндә акча берәмлеге күләме кимиячәк.Бу исә безнең һәрберебезгә дә уңайлык китерәчәк.Хәтта тиен дә кире кайта.Сүз уңаеннан, металл акча берәмлекләре перспективада акча әйләнешен арзанайтуга булышачаклар-аларны кәгазьләр белән чагыштырганда сирәгрәк алыштырырга туры килә.

**-Шулай да күп кешеләр бу акциягә шикләнебрәк карыйлар.Өлкән яшьтәгеләр элеккеге ачы гыйбрәтләрне әле онытмаганнар.**

-Борчылырга урын юк.Деноминация турында биш ай алдан хәбәр ителде.1998 ел дәвамында кибетләрдә,базарларда,киоскларда,даруханәләрдә,вокзалларда,почталарда яңа һәм иске акчалар да кабул ителәчәк,шуңа аларны ашыгып алыштыру хаҗәте юк.Гомумән,2002 ел азагына кадәр һәркем иске акчаларын яңага алыштыра алачаклар.

**-Инде аерым кешеләр ясалма курс буенча алданрак акча алыштырырга теләсәләр? Бу очракта сез нәрсә киңәш итәр идегез?**

-Бу эшне бары мошенник кына эшли ала.Андый кеше турында тиешле органнарга хәбәр бирергә киңәш итәр идем.

**-Кемнәрдер деноминациядән файдаланып бәя күтәрәчәк дигән хәбәрләр йөри.**

-Моны бит бүген дә эшләп була-бездә базар мөнәсәбәтләре.Әмма сатып алучыны бер генә тапкыр алдап була.Товар бүген күп,шуңа да бәяләр элеккеге дәрәҗәгә кайтачаклар.Ә дәүләт тарафыннан көйләнә торган бәяләр шулай ук калачаклар.

**-Сез яңа акча үрнәкләре белән таныштыр. Алар ниндиерәк булачак?**

-Аларның форматы үзгәрми,төсләре дә шулай ук кала.Акчаның һәр ике ягы да безгә таныш рәвештә булачак.Бары өч нуль генә кими-моңа күнәргә туры киләчәк.Әйләнештә 500,100,50;10 һәм 5 сумлык кәгазь акчалар булачак.Металл 1,2,5 сумлыклар пәйда булачак.Тиеннәр кайта,моннан тыш 5,10,50 тиенлек акчалар булачак.Ә менә 3,15,20 тиенлек акчалар булмаячак.

**-Ә бу айларда сезгә деноминация турында сораулар белән мөрәҗәгать итүчеләр булдымы?**

-Юк диярлек.Бу көннәрдә без коммерция банклары бүлекчәләре баш бухгалтерларын , управляющийларын эшлекле сөйләшүгә җыйдык,деноминацияне тыныч,эшлекле шартларда үткәрергә кирәклеген ассызыкладык.

**-РКЦ да эш режимы ел башы һәм ахырында тыгыз буламы?**

-Һәрвакыттагыча, 31 декабрь безнең өчен аерата киеренке көн.2 январь көнне дә гадәти режимда эшлибез.

**-Укучыларыбызга нинди дер теләкләрегез бармы?**

-Һәркемгә игелекле яңа ел килсен! Деноминация беркемнең дә кәефен бозмаска һәм бәйрәм мәшәкатьләренә .комачауламаска тиеш.

**Әңгәмәдәш-Т.Назарова.**

## Игътибар!

**1998 елдан деноминация безгә акча әйләнешенә түбәндәге үзгәрешләрне кертә:**

| Яңа акча | | Иске акча |
|---|---|---|
| 1 тиен | = | 10 сум. |
| 5 тиен | = | 50 сум. |
| 10 тиен | = | 100 сум. |
| 50 тиен | = | 500 сум. |
| 1 сум | = | 1000 сум. |
| 2 сум | = | 2000 сум. |
| 5 сум | = | 5000 сум. |
| 10 сум | = | 10000 сум. |
| 50 сум | = | 50000 сум. |
| 100 сум | = | 100000 сум. |
| 500 сум | = | 500000 сум. |



## Россиянең сугышчан дан көннәре



### 24 декабрь - А.В.Суворов җитәкчелегендәге рус гаскәрләренең Измаилны алу көне

Рус - төрек сугышында (1787 - 1788еллар) Плевна, Кинсбург, Очаков, Рымник өчен сугышларда җиңелгән Төркия, солых төзелүгә дә карамастан, 1790 елда сугыш хәрәкәтләрен кабат яңартып җибәрә.

Россия бу сугышта үз алдына Кара диңгезгә чыгу һәм Балканда үзенең йогынтысын көчәйтүне максат итеп куя. Беренче уңышлар бик җиңел яулана. Ишкәкле флотилия Дунайдан төрек көймәләрен себереп чыгара. Килия, Тульча, Исакча алына. Әмма Дунай тамагында төрекләрнең, Суворов сүзләре белән әйткәндә «йомшак урыннары булмаган» ныгытылган Измаил крепосте тора.

Француз инженерлары тарафыннан үзгәртеп корылган һәм ныгытылган бу крепость чамадан тыш биек вал белән, ә анысы су тутырылган киң канау белән чорнап алынган була, шәһәрнең аңа килү юлларын, капкаларын, бастионнарын 260 орудие саклый. Измаил өчен сакта төрекләрнең» 35 меңлек иң яхшы гаскәрләрдән сайлап җыелган гарнизоны сакта тора.

Руслар үз гаскәрләрен Измаилга таба якынайталар. Бирелергә дигән тәкъдимгә каршы төрекләрнең башлыгы, крепостьны бирүгә караганда үлүебез яхшырак, дип көлеп кенә җавап кайтара.

Рус гаскәрләренең саны 30 меңгә җитә яза, аларның яртысы начар коралланган казаклар була. Солдатларның киемнәре тузып бетә, азык - төлек җитмәве үзен нык сиздерә.

Вакыт уза, ул арада инде салкын һәм юеш көз килеп җитә. Солдатларның да сугышчан рухы төшә. Генераллар Потемкин, Майоров, Гудовичтан торган хәрби совет штурмнан баш тартырга һәм гаскәрне кышкы фатирларга чигереп торырга карар кылалар.

Әмма Екатерина II моңа риза булмый һәм сугышны тизрәк һәм җиңү белән тәмамлауны таләп итә. Ул бөтен гаскәрне үз командалыгына алырга тәкъдим итеп Суворовка чапкын җибәрә.

Суворовның килүе турындагы хәбәр армия һәм флотка тарала һәм «Суворов» дигән сүз үзе генә дә арасында моңарчы күрелмәгән сугышчан рух күтәренкелеге уята. Крепостьны штурмлауга әзерлек башлана. Суворов чатырлар буйлап йөри, солатлар белән сөйләшә, азык - төлек китерергә, күрәк иттереп баскычлар әзерләргә боерык бирә.

Измаилдан читтә сулы канаулы ныгытмаларына кадәр ясап шуңа охшаш крепость төзелә. Солдатлар төннәрен монда килеп шул канау аркылы чыгарга, ныгытма вал өстенә менәргә, штык сугышына өйрәнәләр. Флангларда яңа батареялар корыла.

Крепостьны Дунайдан да десант төшереп өч яктан берьюлы штурмларга карар кылына.

Мәгънәсез кан коюны булдырмас өчен Суворов Мехметкә креспотьны бирергә тәкъдим итеп язу җибәрә. «Уйларга 24 сәгать вакыт - сезнең иркегез; минем яктан беренче туп атуы - иркегез бетә башлавы; штурм - үлем» диелгән була анда. Төрекләр крепостьны сугышсыз бирүдән баш тарталар.

Рус гаскәрләре атакага тотынып өчен башлангыч позициягә урнашалар. 24 декабрь иртәсендә һавага сигнал ракетасы очырыла. Солдатлар штурмга күтәреләләр. Канау аркылы баскычлар салып узалар, ә аннан баскычларны икешәрләп бәйләп вал стенасына менәләр. Төрекләр мылтык һәм картечьлардан рәхимсез ут ачалар. Күп югалтуларга да карамастан, рус гаскәрләре төрекләрнең кылыч һөҗүмнәренә каршы штык атакасы ясыйлар. Сугыш кызганнан кыза бара, һәркайда русча «ура!» яңгырый.

Гренадерлар, карабинерлар һәм гусарлар ачык капкадан крепость эченә атыла. Төрекләр кыю төстә каршы торалар, һәр йорттан ядрәләр оча. Постоялый дворлар үзләре кечкенә крепостьларга әверелә. Рәхимсез штык сугышында аны чолгап алган берничә мең төрек белән Пирей үтерелә. Сераскир Мехмет та шундый ук язмышка дучар була. Дошманның каршылыгы бастырыла, Измаил алына.

Бу сугышта төрекләрнең 26 мең сугышчысы үлә, 9 мең кешесе әсирлеккә алына. Русларның 4 мең кешесе үлә, 6 меңе яралана. Руслар 245 туп, 3 мең пот дары, 341 байрак, 10 меңләп ат кулга төшерәләр.

Измаилның яулануы Төркиягә һәм Россиянең дошманнарына гаять көчле тәэсир ясый. Суворовның бу данлыклы җиңүе рус коралының һәм рус сугыш сәнгатенең бөтен дөньяда данын арттыра һәм рус - төрек сугышының тәмамлануын тизләтә.

**Язманы И.САНДЛЕР әзерләде.**

---

# Тиеннәр һәм берлек кире кайта

***Январьда безне нәрсә көтә дигән сорауга һәркем уйлап та тормыйча җавап бирә:яңа 1998 ел башы һәм денаоминация.Беренчесе белән гадәттә иң якты өметләр бәйләнсә,икенчесе шулай ук борчылырга нигез калдырмый, акча алышынмый,кешеләргә ашыга-кабалана чиратка йөгерәсе юк.Бары иске акча берәмлекләрен акрынлап әйләнештән чыгаралар һәм яңа,элек без күнгән берәмлекләр кире кайтачак.Нульләре кимегән яңа куперлар әйләнешкә керүгә берничә көн генә калды,шуңа без Норлат расчет-касса үзәге начальнигы Асия Котбетдиновна Сафиуллинага бу җәһәттән берничә сорау белән мөрәҗәгать иттек.***

**Беренче куллардан**

**-Асия Котбетдиновна,деноминация районда сездән башлангыч ала булып чыга.Тагын бер кат аның эчтәлеген аңлатсагыз иде.**

-Деноминация-бу инфляция тукталу, икътисад стабильләшү,акча керемнәре үсүгә күргәзмә дәлил.Һәм ул барлык акча әйләнешен гадиләштерү һәм арзанайту өчен башкарыла,чөнки бәяләрнең яңа масштабына хезмәт күрсәткәндә акча берәмлеге күләме кимиячәк.Бу исә безнең һәрберебезгә дә уңайлык китерәчәк.Хәтта тиен дә кире кайта.Сүз уңаеннан, металл акча берәмлекләре перспективада акча әйләнешен арзанайтуга булышачаклар-аларны кәгазьләр белән чагыштырганда сирәгрәк алыштырырга туры килә.

**-Шулай да күп кешеләр бу акциягә шикләнебрәк карыйлар.Өлкән яшьтәгеләр элеккеге ачы гыйбрәтләрне әле онытмаганнар.**

-Борчылырга урын юк.Деноминация турында биш ай алдан хәбәр ителде.1998 ел дәвамында кибетләрдә,базарларда,киоскларда,даруханәләрдә,вокзалларда,почталарда яңа һәм иске акчалар да кабул ителәчәк,шуңа аларны ашыгып алыштыру хаҗәте юк.Гомумән,2002 ел азагына кадәр һәркем иске акчаларын яңага алыштыра алачаклар.

**-Инде аерым кешеләр ясалма курс буенча алданрак акча алыштырырга теләсәләр? Бу очракта сез нәрсә киңәш итәр идегез?**

-Бу эшне бары мошенник кына эшли ала.Андый кеше турында тиешле органнарга хәбәр бирергә киңәш итәр идем.

**-Кемнәрдер деноминациядән файдаланып бәя күтәрәчәк дигән хәбәрләр йөри.**

-Моны бит бүген дә эшләп була-бездә базар мөнәсәбәтләре.Әмма сатып алучыны бер генә тапкыр алдап була.Товар бүген күп,шуңа да бәяләр элеккеге дәрәҗәгә кайтачаклар.Ә дәүләт тарафыннан көйләнә торган бәяләр шулай ук калачаклар.

**-Сез яңа акча үрнәкләре белән таныштыр. Алар нинднерәк булачак?**

-Аларның форматы үзгәрми,төсләре дә шулай ук кала.Акчаның һәр ике ягы да безгә таныш рәвештә булачак.Бары өч нуль генә кими-моңа күнәргә туры киләчәк.Әйләнештә 500,100,50,10 һәм 5 сумлык кәгазь акчалар булачак.Металл 1,2,5 сумлыклар пәйда булачак.Тиеннәр кайта,моннан тыш 5,10,50 тиенлек акчалар булачак.Ә менә 3,15,20 тиенлек акчалар булмаячак.

**-Ә бу айларда сезгә деноминация турында сораулар белән мөрәҗәгать итүчеләр булдымы?**

-Юк диярлек.Бу көннәрдә без коммерция банклары бүлекчәләре баш бухгалтерларын , управляющийларын эшлекле сөйләшүгә җыйдык,деноминацияне тыныч,эшлекле шартларда үткәрергә кирәклеген ассызыкладык.

**Игътибар!**

**1998 елдан деноминация безгә акча әйләнешенә түбәндәге үзгәрешләрне кертә:**

| Яңа акча | Иске акча |
|---|---|
| 1 тиен | = 10 сум. |
| 5 тиен | = 50 сум. |
| 10 тиен | = 100 сум. |
| 50 тиен | = 500 сум. |
| 1 сум | = 1000 сум. |
| 2 сум | = 2000 сум. |
| 5 сум | = 5000 сум. |
| 10 сум | =10000 сум. |
| 50 сум | = 50000 сум. |
| 100 сум | = 100000 сум. |
| 500 сум | = 500000 сум. |



**-РКЦ да эш режимы ел башы һәм ахырында тыгыз буламы?**

-Һәрвакыттагыча, 31 декабрь безнең өчен аерата киеренке көн.2 январь көнне дә гадәти режимда эшлибез.

**-Укучыларыбызга ниндидер теләкләрегез бармы?**

-Һәркемгә игелекле яңа ел килсен! Деноминация беркемнең дә кәефен бозмаска һәм бәйрәм мәшәкатьләренә .комачауламаска тиеш.

**Әңгәмәдәш-Т.Назарова.**

## Мәгариф тормышы

**Ноябрь азагында Яр Чаллы шәһәрендә «Милли мәгарифтә инновацион технологияләр: эзләнүләр, тәҗрибә» дигән темага шәһәр (район) мәгариф идарәсе (бүлеге) башлыкларының милли белем һәм тәрбия бирү буенча урынбасарларының республика семинар - киңәшмәсе үткәрелә. Анда безнең район мәгариф бүлегенең әйдәп баручы белгече Әлфия Вазыйх кызы Гобәйдуллина да катнашты. Аның семинар - киңәшмәдә алган фикерләре белән бүлешүне үтенгәч улы: «Чаллы мәктәпләренә кертелгән һәм хәзер дә кертелә торган яңа технология буенча укыту һәм тәрбияләү яңа, белгечләр әйтүенчә, нәтиҗәле, перспективалы баскычка басты-ра. Һәм бу технологиянең бүгеннән безнең мәктәпләрдә дә нигезле урын алуы шик тудырмый»- диде. Шуңа да яңа технологиянең асылы, Чаллы шәһәрендә милли телләргә караш турында аның эчтәлекле әңгәмәсе укучыларга да кызык булыр дип уйлыйбыз.**

# Яр Чаллы тәҗрибәсе

- 3 көн дәвамындагы семинар - киңәшмәдә Татарстан мәгариф министры Ф.Ф.Харисов, Яр Чаллы шәһәре хакиме, шәһәрдәге өзлексез педагогик белем бирү институты фәнни хезмәткәрләре, яңа дәреслекләр авторлары һәм башкалар белән очраштык, Яр Чаллы мәктәпләре укытучыларының иҗади үсеш дәресләре, рус телле балаларның татар телен өйрәнү проблемалары белән таныштык.

Менә 6 еллап инде Чаллы шәһәре хакимиятендә милли бүлек, хәзерге көндә идарә эшли. Башка идарә һәм бүлекләрдә боерык нигезендә Телләр турындагы законны тормышка ашыру буенча җаваплы белгечләр эшли. Мәктәп директорлары, балалар бакчалары мөдирләре, кибет җитәкчеләре белән төзелгән контрактларга әлеге законны үтәү турында пункт кертелгән. Гомумән, чаллылылар республикада беренчеләрдән булып, Телләр турындагы законны тормышка ашыру программасын кабул итәләр, аңа максатчан рәвештә шәһәр бюджетының 1 процентына кадәр акча тотыла.

Шәһәрдә 530 мең кеше яши. 87 милләт вәкиле. Мәктәпләрдә 120 меңнән артык бала белем ала. Балалар бакчаларының барысында да татар теле укытыла, һәр комплекста бер татар балалар бакчасы булдыру буенча эш алып барыла. Урта белем бирү йортларында татар балаларының 52,6 проценты татарча укый. Татар теле буенча имтиханнар 11нче сыйныфка кадәр үткәрелә (республикада 5нче сыйныфка кадәр). Соңгы 3 елда гына Чаллыда 32 төрле программа, методик кулланмалар, дәреслекләр, китаплар бастырылып чыга. Якшәмбе мәктәпләре оеша.

Педагогикада елдан - ел төрле тәҗрибәләр, юнәлешләр туып тора һәм күбесе искергән мода сыман онытыла бара. Шулай да алар педагогик тәҗрибәне баета, уку - укыту эшенә уңай йогынты ясый. Ә менә чех педагогы Я.А.Коменскийның «Бөек дидактика» исемле мәшһүр хезмәте 340 ел элек дөнья күрә һәм хәзер дә яши. Шуңа нигезләнеп «Психодидактика» исемле яңа фән туа. Аңа нигез 1975 елда Башкорт дәүләт педагогия институтының Әхмәт Рәхимов җитәкчелегендәге укучыларның иҗади фикер йөртү мәсьәләләрен өйрәнүче лабораториясендә салына. Психодидактика фәненең максаты - укучыларның аң - белеме үсешен, иҗади мөмкинлекләрен, рухи сыйфатлары дәрәҗәсен баету.

**- Рәхимов ысулы нидән гыйбарәт соң?**

- Элек яңа ачышлар, ысуллар методика дип аталса, Рәхимов үзенең ачышын - технология дип атый. Тулырагы - үстерелешле укыту технологиясе. Технология - грек сүзе, техно (осталык) һәм логос (мәгълүмат) тамырларыннан тора, димәк, осталык турында мәгълүматлар җыелмасы дигәнне аңлата. Әйтик, Давыдов - Занков методикасы укытучы эшчәнлегенә юнәлсә, Рәхимовның - балага. Бу технологиянең уңай яклары күп. Без караган ачык дәресләр шуның мисалы булып торалар.

Үстерелешле укыту технологиясе баланы логик фикер йөртергә, чагыштырырга, куелган мәсьәләләрне чишеп нәтиҗәләрен күрә белергә өйрәтә. Традицион алымнарга корылган дәресләрдә төп фигура - укытучы, ә менә Рәхимов технологиясе, киресенчә, баланы шәхес итеп тәрбияләүне максат итеп куя, укучы төп фигура итеп карала. Технология хәзер Клайпедодан алып Усть - Илим шәһәренә кадәр булган территориядә кертелә. Мәсәлән, Усть - Илим шәһәрендә 1989 елдан бирле 70ләп мәктәп шушы технология буенча эшләп, 2 баллы системага күчәләр, ягъни «4» һәм «5» билгеләре генә куялар. Чаллыда да бу система беренче урынга чыккан.

Рәхимов технологиясе 1992 елда гыйльми - тикшеренү мәктәпләре арасында РФ күләмендә җиңеп чыга, Новгородта, Симферопольдә, Татарстанда һәм башка җирләрдә филиаллар эшли. Технология чит илләрдә, бигрәк тә Германия, Голландия һәм башкаларда кызыксыну уята.

Яңа технология кертү яңа дәреслекләр булдыруны таләп итә. Шул максаттан, үстерелешле укыту технологиясенә нигезләнгән «Әлифба», 1 - 3 сыйныфлар өчен татар теле, «Өмет - 1» (уку китабы) уку әсбапларын бер - бер артлы укучылар өстәленә куюга ирешелә. Шунысы куанычлы, китап авторларының берсе безнең якташыбыз Кәкре Атау авылы кызы Зәйтүнә Шәмсетдин кызы Шәмсуарова да бар.

Әлеге яңа дәреслекләр җирле компонентка таянып, кызыклы һәм эчтәлекле итеп төзелгән, гадәти дәреслекләрдәгечә күнегүләр күчереп язуга гына кайтып калмаган, ә уйлана торган итеп бирелгән. Алар укучыларның логик фикерләвен, сөйләм эшчәнлеген, белем нигезләрен тирәнтен формалаштыруга корылган, баланы халык педагогикасы нигезендә тәрбияләүгә зур игътибар бирелгән.

Мәктәптә үстерелешле тәрбия алып бару - фәндә әле махсус өйрәнелмәгән. Бу яктан да Чаллыда боз кузгалган инде. Ә.Рәхимовның турыдан - туры җитәкчелегендә лаборатория методисты В.Казыйханов «Әхлак дәресләре» әсбабын яза. Аны кулланмаган мәктәп юк. Чаллыда әлегә 9 мәктәптә әхлак дәресләре предмет буларак уку планына кертелгән. Укытучылар, балалар һәм ата - аналар бу дәресләргә югары бәя куялар.

**- Әлфия Вазыйховна, яңа технология безнең мәктәпләргә кирәкме?**

- Әлбәттә, әлеге яхшы нәтиҗәле һәм перспектив саналган технологияне мәктәпләргә кертү бүген мөһим мәсьәлә. Мин укытучыларга танышу өчен яңа дәреслекләр, методик әсбаплар алып кайттым. Февраль аенда шул темага 2 нче семинар Түбән Кама шәһәрендә үткәреләчәк. Анда без, башлангыч тәҗрибәбезне тәкъдим итәргә тиешбез.

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА сөйләште.**

## Белдерүләр  Белдерүләр

**Норлат район элемтә узелын 1998 елның 1 нче гыйнварыннан Норлат электр элемтәсе узелы һәм почта элемтәсе узелы итеп реорганизацияләү сәбәпле, элемтә узелы бурычлы абонентлар, предприятие, оешма, учреждение җитәкчеләрен элемтә хезмәтләре өчен бурычларын 28 нче декабрьгә кадәр түләүләрен мәҗбүр итә.**

**Бурыч түләнмәгән очракта элемтә Министрлыгының 21.09.97 нче елгы 111/1010 номерлы телеграммасы нигезендә телефоннарны өзү һәм әлеге номерларны түләүгә сәләтле клиентларга тапшыру буенча чаралар күреләчәк.**

РУС администрациясе.

**ЖКХ МППсы фатирларында торучы һәм элек коммуналь хезмәтләр өчен МПП конторасына түләүчеләр 1997 нче елның 1 нче декабреннән түләүләрне НГДУ ЖКХсының элекеге конторасында башкарырга тиешләр** (чистарту корылмалары янында).

«Норлат машина төзү заводы» АҖсе кибетендә (Спортивная ур., 1) Норлат районы пенсионерлары пенсия хисабына промышленность товарлары ала алалар. Үзегез белән паспорт һәм пенсия таныклыгы булу шарт.

Администрация.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Норлат шәһәрендә яшәүче хөрмәтле киявебез, җизнәбез **Әхәт Салих улы Вәлитовны** 50 яшь тулу уңае белән кайнар котлыйбыз. Саулык, озын гомер, чиксез бәхет телибез.

Кояш гомере бирсен сиңа ходай,
Шатлыкларың килсен өелеп.
Саулык - сәламәтлек юлдаш булсын,
Бәхетләргә яшә төренеп.

**Гафуровлар, Сабировлар, Курамшиннар гаиләләре.**

Яңа Иглай авылында яшәүче киң күңелле, кайгыртучан, бөтен шәфкатьлелекне үзенә сыйдырган кадерле әниебез **Нәгыймә Бәдретдин кызы Бикиниеваны** туган көне белән котлыйбыз.

Әниебез безнең, синең күңелең изге,
Бул син, зинһар, озын гомерле.
Кылган шәфкать, изгелегең өчен
Син хөрмәтле безгә, кадерле.

**Кызларың, кияүләрең, улларың, киленнәрең, оныкларың.**

## БЕЛДЕРҮЛӘР

### САТАБЫЗ

**Ашыгыч рәвештә 1997 нче елның сентябрендә чыккан тентлы, люкс УАЗ - 33036.** Тел.: 5 - 21 - 94.

***

**ВАЗ - 21099**. Адрес: Нефтьчеләр ур., 9 - 16.

***

**УАЗ - 469**. Адрес: Карбышев ур., 12.

***

**ВАЗ - 2101**. Адрес: Завод тыкрыгы, 6 - 15.

***

**Көнчыгыш микрорайонында төзелешләре белән участок. Гаражы, мунчасы, төзелеп бетмәгән йорты бар.** Адрес: Школьная ур., 16 - 9, тел.: 2 - 19 - 13.

***

**Уңайлы урында төзелеш материаллары белән төзелеп бетмәгән кибет.** Азык - төлек базарында «Можар» ларегына мөрәҗәгать итәргә.

***

**«Муравей» мотороллеры**. Тел.: 5 - 21 - 65.

***

***ВАЗ - 21011, кыйммәт түгел.*** Тел.: 5 - 24 - 52.

***

**Сыер ите һәм бозау**. Тел.: 2 - 25 - 16.

***

**Завод тыкрыгы янындагы чокыр янында чанада металл гараж**. Тел.: 2 - 16 - 98.

***

**1996 нчы елгы ВАЗ - 2106. Тел**.: 2 - 26 - 05, 18 сәг.тән соң.

***

**Ключи поселогында йорт сатыла яки фатирга алыштырыла.** Тел.: 5 - 20 - 54, 16 сәг.тән соң.

**1985 нче елгы ВАЗ - 2107, двигателе 2105**. Тел.: 2 - 27 - 57 (эш), 2 - 22 - 85 (өй).

***

**ВАЗ - 2103, бәясе 12,5 млн. сум.** Адрес: Фрунзе ур., 9.

***

**Циолковский урамында ике бүлмәле фатир.** Тел.: 5 - 12 - 35, 17 сәг.тән соң.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**Литвинов В.А. исеменә документлар белән сумка табучыны бүләк бәрабәренә түбәндәге адреска иясенә кайтаруын сорыйбыз.** Дружба ур., 69 - 3, тел.: 5 - 20 - 37.

***

**Бурычка акча алабыз**. Тел.: 2 - 23 - 90.

**Район мәгариф бүлеге коллективы Биккол мәктәбе укытучысы Илгиз Нурлыгаян улы Мөбәрәкшинның вакытсыз вафат булуы уңаеннан аның гаиләсенең авыр хәсрәтен уртаклаша.**


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

**Учредительләр:Норлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2338 данә.